Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында" 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (I өлеш); 2009, № 6; Ватаным Татарстан, 2011, 11 май, 2 август) үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

"Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында" 2011 елның 1 августындагы 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Ватаным Татарстан, 2011, 2 август) юкка чыгарырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 10 ноябре
№ 79-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ